| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Яңа Иглай ав. КАРАР

«09» ноябрь 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Үзәк урам 13 нче йорт адресы буенча урнашкан кибет янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай торак пунктында Үзәк урамындагы 2 - 28, 1 - 7, Пушкин, Җиңү, Гагарин, Чапаев, Яшьләр урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Үзәк урам 17 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай торак пунктында Үзәк урамындагы 30 - 72, 15 - 57, Елга тыкрыгы, Үзәнлек тыкрыгы, Үзәнлек урамы, Тау урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Үзәк урам 17 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай торак пунктында Үзәк урамындагы 30 - 72, 15 - 57, Елга тыкрыгы, Үзәнлек тыкрыгы, Үзәнлек урамы, Тау урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Яңа Иглай авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Яңа Иглай авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк граждannардан кала 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Яңа Иглай торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

2.Яңа Иглай торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

3. Урамнарны яктыртуны оештыру өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу»

4. Янгынга каршы куркынычсызлык буенча товарлар сатып алу (янгын сүндерү краны һәм җиһсәләр, көпшәләр)

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Фәйзуллин